# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Сарабиккол авыл җирлеге составына керүче Сарабиккол торак пунктында узган гражданнар җыены карары

17 ноябрь 2019 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Сарабиккол авыл җирлеге составына керүче Сарабиккол торак пунктында гражданнар җыены турында КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. 2020 елда Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Сарабиккол авыл җирлеге составына керүче Сарабиккол торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлардан, тыл хезмәтчәннәреннән, күп балалы гаиләләрдән тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Әлеге средстволарны түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә:

-территорияне төзекләндерү һәм яшелләндерү;

-янгын сүндерү техникасын тоту гаражын ремонтлау;

- мәдәният йорты территориясен төзекләндерү.

Гражданнар җыелышында рәислек итүче,

Сарабиккол авылы җирлеге башлыгы Г.Р.Гаделшина